ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Кильдеево

07.11.2025 2

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Харино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 19 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Харино авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Харино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 750 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Харино авылы Нагорная урамы адресы буенча (һәйкәл янында) 10.30 сәгатьтә үткәрергә.

4. Җыенны оештыручы итеп Килди авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В.М.Бурдин